**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Урал торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

13 ноябрь 2024 ел №16

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Урал торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, тормыш иптәшләреннән), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 500 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (Урал торак пунктындагы зират территориясендәге коймаларны ремонтлауга (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Урал торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә (Урал торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев